Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

20 декабрь 2019 ел № 80

Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 5 өлешенә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә

Колшәрип авыл Советы КАРАР кабул итте:

1.Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында кушылып бирелгән Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Колшәрип авыл Советының 2019 елның «15»мартындагы 64 номерлы «Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) халыкка игълан итәргә, Колшәрип торак пункты территориясендә урнашкан мәгълүмат стендында һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Колшәрип авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

Колшәрип авыл җирлеге Башлыгы Т.М. Бурмистрова

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы
«20» декабрь 2019 ел № 80
карарына1 нче кушымта

Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә

## 1.Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 5 өлеше нигезендә кабул ителгән элеге Нигезләмә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмә белән Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы (алга таба-Әлмәт муниципаль районы) бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге (алга таба - авыл җирлеге)бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба-Субсидияләр)

## 2. Субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә.

2.2. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр Колшәрип авыл җирлеге бюджеты керемнәре хисабыннан бирелә.

2.3. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр бюджет керемнәренең классификациясе нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетының керем өлешендә чагылдырыла.

2.4. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр, шул исәптән муниципаль программаларны, Колшәрип авыл җирлегенең ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыру кысаларында бирелә.

2.5. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр күләмен исәпләү Әлмәт муниципаль районы бюджетына әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә башкарыла.

2.6. Субсидияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Колшәрип авыл җирлеге бюджеты турындагы карарда яки чираттагы финанс елына һәм план чорына Колшәрип авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү һәм Колшәрип авыл җирлеге бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү юлы белән раслана.

2.7. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр чираттагы финанс елына һәм план чорына Колшәрип авыл җирлеге бюджеты турында карар белән расланган сумма чикләрендә һәм Колшәрип авыл Советы карары нигезендә бирелә.

2.8. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр Әлмәт муниципаль районы бюджетына Колшәрип авыл Советы карарына туры китереп, Колшәрип авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр (әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы) нигезендә бирелә.

2.9. Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр бирү турындагы килешүдә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) Субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

2) Субсидияләр бирү һәм аларны тоту шартлары;

3) Субсидияләр бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

4) Субсидияләр күчерү тәртибе;

5) Субсидияләр бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

7) финанс тәэминаты чыганагы булган Субсидия чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

8) башка шартлар.

2.10. Килешүләр төзү тәртибе Колшәрип авыл җирлеге Уставы һәм (яисә) Колшәрип авыл Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2.11. Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидияләр бирү турындагы килешү проектын әзерләү Колшәрип авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүче һәм субсидияләр күчерүче Колшәрип авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.12. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр, Әлмәт муниципаль районы белән килешү төзегәннән соң, агымдагы елның һәр аеның 25 числосына кадәр ай саен бирелә.

2.13. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр Әлмәт муниципаль районы бюджетының касса үтәлешен гамәлгә ашыручы органда ачылган бердәм счетына акча күчерү юлы белән Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелә.

2.14.Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына карата файдаланылмаган Субсидияләр калдыклары буенча операцияләр (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пункты нигезендә):

1) Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата кулланылмаган, Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелгән һәм максатчан билгеләнеше булган Субсидияләр агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Колшәрип авыл җирлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

2) Колшәрип авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш администраторы тарафыннан әлеге пунктның 1) пунктында күрсәтелгән финанс хисап елында кулланылмаган Субсидияләргә ихтыяҗ булу (булмау) турында карар кабул итү, шулай ук аларны Әлмәт муниципаль районы бюджетына кире кайтару, аларга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә әлеге акчалар Колшәрип авыл җирлеге бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып күрсәтелгән Субсидияләр килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелгән Әлмәт муниципаль районы бюджеты чыгымнары турындагы хисап нигезендә гамәлгә ашырыла.

3) Колшәрип авыл җирлеге бюджеты акчалары Субсидияләргә ихтыяҗ булу турындагы баш администраторының карары нигезендә, Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелгән һәм финанс органы белән билгеләнгән тәртиптә файдаланылмаган максатчан билгеләнештәге Субсидияләргә

булган ихтыяҗлар күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган күләмдә, күрсәтелгән Субсидияләрне бирү максатларына туры килгән Әлмәт муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен, агымдагы финанс елында Әлмәт муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

4) Әлеге пунктның 3) пунктчасында каралган карарларны кабул итү тәртибе җирле администрациянең җирле бюджетлардан бюджетара трансфертларны кире кайтару тәртибен җайга салучы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

5) 1 гыйнварга файдаланылмаган субсидияләр Колшәрип авыл җирлеге бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Колшәрип авыл җирлеге бюджеты керемнә кайтарылырга тиеш.

2.15. Субсидияләр түбәндәге очракларда Колшәрип авыл җирлеге бюджетына кайтарылырга тиеш:

- аларны максатчан файдаланмауны ачыклау;
- Әлмәт муниципаль районының хисаплылыгын тапшырмау;
- хисаплылыкта дөрес булмаган белешмәләр тапшыру.

2.16. Әлмәт муниципаль районы тарафыннан Субсидия ирекле тәртиптә кире кайтарылмаган очракта, күрсәтелгән акчалар Колшәрип авыл җирлеге бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә кайтарылырга тиеш.

## 3. Субсидияләрне файдалануга контроль һәм хисап тоту.

3.1. Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан алынган Субсидияләрнең максатчан кулланылышы һәм алардан файдалану турындагы хисапларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Субсидияләрне куллануны Колшәрип авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Әлмәт муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы контрольдә тота.

3.3. Субсидияләрдән файдалану турында хисап Колшәрип авыл җирлегенә Финанс - бюджет палатасы тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча тапшырыла.

Җирле үзидарә органнарының җирле
әһәмияттәге мәсьәләләрнехәл итү буенча
вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә
торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу
максатларында Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципаль районы бюджетына
Татарстан РеспубликасыӘлмәт
муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге
бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе
һәм шартлары турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр күләмен исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына (алга таба - Әлмәт муниципаль районы) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге (алга таба - авыл җирлеге) бюджетыннан Субсидияләрнең гомуми күләмен хисаплап чыгару өчен билгеләнгән.

2. Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру буенча Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Субсидияләр күләме ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Колшәрип авыл җирлеге бюджеты проектын төзегәндә Колшәрип авыл җирлегенең суммар ихтыяҗлары һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендәге аермадан чыгып билгеләнә.

3. Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру буенча барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = (Д1 + Д2) – (Р + С),$$

монда:

S–авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидия күләме;

Д1 - авыл җирлегенең Россия Федерациясе бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә беркетелгән керемнәре;

Д2 – авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Әлмәт муниципаль районыннан дотацияләр (Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән);

Р – Әлмәт муниципаль районының берләштерелгән (консолидирванный) бюджетын формалаштыруга бердәм төп алымнар нигезендә төзелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

С – Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә авыл җирлеге бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.

Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәтмуниципаль районы бюджетына Татарстан РеспубликасыӘлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында килешүнең типлаштырылган формасы

«__» _____________ 20__ел. №  ______________
(килешүтөзүдатасы) (килешүномеры)

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ____________________
(шәһәр, авыл җирлеге исеме)
Башкарма комитеты, алга таба «Авыл җирлеге» дип аталучы, исеменнән
__________________________________________________________________
(җирлекнең башкарма хакимият органы җитәкчесе яки аның вәкаләтле вәкиле вазыйфасы исеме)
_____________________________________________, гамәлдә булган нигездә
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта))
__________________________________________________________________,
(башкарма хакимият органы турында нигезләмә, вәкаләтләрне таныклаучы ышаныч кәгазе, боерык яки башка документ)
Бер яктан, һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба «Район» дип аталачак, йөзеннән
_______________________________________________________________
*(муниципальхакимиятнеңбашкарма органы җитәкчесе яки аңавәкаләтлезатвазыйфасыисеме)*
_____________________________________________, гамәлдә булган нигездә
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта))
__________________________________________________________________,
(устав, ышанычкәгазе яки вәкаләтләрентаныклаучы башка документ)
Икенче яктан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Совет карары нигезендә алга таба «Яклар» дип аталган
__________________________________________________________________
(шәһәр, авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме)
«___» _____________ № ___ «__________________________________»,
(Чираттагыфинанселынаһәм план чорынашәһәр, авылҗирлеге бюджеты турында карар)

түбәндәгеләр турында әлеге Килешү төзелде.

1. Килешү Предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып 20 _ елда  һәм 20_- 20_  елларда җирлек бюджетыннан муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карп тоту өчен шартлар булдыру буенча Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, район бюджетына җирлек бюджетының бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә, бюджет чыгымнарының классификациясе кодлары буенча (алга таба – БК кодлары) субсидияләр бирү тора:
Авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүченең коды________, _ _ _ _ кисәк, бүлекчә ___________, максатчан статья ______________, чыгымнар төре_____.

2. Районның чыгым йөкләмәләрен үтәү
максатларында бирелә торган субсидияләрне финанс белән тәэмин итү

2.1. Әлеге Килешү нигезендә Авыл җирлеге бюджетыннан район бюджетына бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләмен тәшкил итә:
20___ елда ____________ (_______________) сум _____________тиен,
(сумма язмача)
20___ елда ____________ (_______________) сум ______________тиен,
(сумма язмача)
20___ елда ____________ (_______________) сум ______________тиен,
(сумма язмача)

3. Субсидия бирүтәртибе, шартларыһәманыкүчерүсроклары

3.1. Субсидияләр Авыл җирлеге Советының финанс елына һәм20_ -20_ нче еллар план чорына бюджет турында (Авыл җирлеге бюджетының җыелма бюджет язмасы) Карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм җирлекнең бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.
3.2.  Субсидияләр түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:
а) әлеге Килешүнең 2.1 пунктында каралган күләмдә үтәү максатларында субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү өчен Районда бюджет ассигнованиеләре булу;
б)Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле чыгымнарын гамәлгә ашыру;
в) Районда субсидиядән файдалану турында хисап бирү.
г) _____________________________________________________________.
3.3. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен авыл җирлеге бюджетыннан Район бюджетына бирелә торган субсидияне күчерү, авыл җирлеге бюджетының факттагы үтәлешен исәпкә алып, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә ай саен 25 числога кадәр гамәлгә ашырыла.

4. Якларныңүзарахезмәттәшлеге

4.1. Авыл җирлеге бурычлы:
4.1.1. Район бюджетына әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартлары үтәлгәндә, _______финанс елына һәм 20_ - 20_елларның план чорына бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Район бюджетына субсидияләр бирүне тәэмин итәргә.

4.1.2. РайонныңсубсидияләрбирүшартларынһәмәлегеКилешүдәкаралган башка йөкләмәләрнеүтәүнеконтрольдәтотуны гамәлгә ашыру.

4.1.3. Субсидия бирүне туктатып торган очракта районга мондый тукталышның сәбәпләре турында хәбәр итәргә кирәк.

4.1.4. Районга, әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә, Район мөрәҗәгатен алган көннән алып 5 эш көне эчендә әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар җибәрергә.

4.1.5. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә:

4.1.5.1. ______________________________________________________;

4.1.5.2. ______________________________________________________.

4.2. Авыл җирлеге түбәндәгеләргә хокуклы:

4.2.1. Районнан Килешүдә каралган субсидияләрне һәм башка йөкләмәләрне, шул исәптән бухгалтерлык исәбе һәм район тарафыннан Субсидияләр бирү шартлары үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны соратып алырга.

4.2.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыру:

4.2.2.1. ______________________________________________________;

4.2.2.2. ______________________________________________________.

4.3. Район түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

4.3.1. Әлеге Килешүнең 3.2 пунктында билгеләнгән субсидия бирү шартларын үтәүне тәэмин итәргә.

4.3.2. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмә белән Авыл җирлеге бюджетына акчаны кире кайтару турындагы нигезләмәләр каралган булса, Авыл җирлеге бюджетына акчаны кире кайтару буенча Авыл җирлеге таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.

4.3.3.Субсидияләр алынган елдан соң киләсе елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта формасы буенча, Авыл җирлегенә субсидия чыгымнары турында хисапларны электрон документ рәвешендә тапшыруны тәэмин итәргә.

4.3.4Запрос булган очракта, районга субсидия бирү шартларын һәм әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрне, шул исәптән бухгалтерлык исәбе белешмәләрен һәм районның субсидия бирү шартларын үтәүгә бәйле беренчел документларны башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм материалларны Авыл җирлегенә бирүне тәэмин итәргә.

4.3.5. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Авыл җирлеге бюджетына кире кайтарырга.

4.3.6. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә:

4.3.6.1. ______________________________________________________;

4.3.6.2. ______________________________________________________.

4.4. Район хаклы:

4.4.1. Әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле аңлатмаларны сорап, Авыл җирлегенә мөрәҗәгать итәргә.

4.4.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга:

4.4.2.1. ______________________________________________________;

4.4.2.2. ______________________________________________________.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. ӘлегеКилешү буенча үз вазыйфаларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә, Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләрне яисә башка документларны рәсмиләштерү белән сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгәндә, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

Әлеге Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш итү хокукына ия булган затлар тарафыннан имзалана һәм Яклар тарафыннан әлеге килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

Әлеге Килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта Якларның әлеге Килешү буенча йөкләмәләре туктатыла.

6.3. Әлеге Килешүне үзгәртү Яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүгә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.4. Әлеге Килешүне Якларның ризалыгы булганда өзәргә мөмкин.

7. Якларның түләү реквизитлары:

| Авыл җирлегенең исеме | Районның исеме |
|---|---|
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| Банк реквизитлары: | Банк реквизитлары: |
| БИК һәм Россия Банкы учреждениесе исеме<br>Исәп-хисап<br>Шәхсиисәп<br>Федераль казначылыкның шәхси счет ачылган территориаль органы исеме<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО | БИК һәм Россия Банкы учреждениесе исеме<br>Исәп-хисап<br>Шәхсиисәп<br>Федераль казначылыкның шәхси счет ачылган территориаль органы исеме<br>ИНН/КПП Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре администраторы<br>ОГРН<br>ОКТМО<br>Район бюджетына кергән субсидия акчалары исәпкә алына торган керемнәрнең бюджет классификациясе коды |

IX. Якларның имзалары

| Авыл җирлегенең кыскартылган исеме | Районның кыскартылган исеме |
|---|---|
| _______________ / _________________<br>(имза) (инициаллар, фамилия) | _______________ / _________________<br>(имза) (инициаллар, фамилия) |

Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районы
Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан
Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы бюджетына җирле әһәмияттәге
мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле
үзидарә органнары вәкаләтләрен
үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым
йөкләмәләрен финанслашу максатларында
субсидияләр бирү турында килешүгә
1 нче кушымта

Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап тоту өчен шартлар тудыруга Әлмәт муниципаль районы бюджетының чыгымнары турында
________________________20__ елның торышы буенча хисап

Вакытлылык: еллык

Үлчәү берәмлеге:*сум*

| Чыгымнар юнәлеше | Акча каралган | Фактта хисап датасына карата килде | Фактта хисап датасына акча кулланылды | Хисап датасына калган акчалар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Әлмәтмуниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе_____________ ______________
(имза)
Финанс-бюджет палатасырәисе___________ ______________
*(имза)*

Башкаручы____________________________
*(Ф.И.О., вазыйфа, бүлекчә)*